ГЛАВА
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Колхозная, дом 2,
село Матаки, 422473
ИНН 1617003243

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Колхоз урамы, 2нче йорт,
Матак авылы, 422473

Тел.: (84375) 3-81-17, факс: (84375) 3-81-18, e-mail: Matak.Drz@tatar.ru,

**с.Матаки**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 ноябрь 2021ел №26

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең Мочали авылында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советынын 02.10.2009 ел, № 46/1 (15.11.2019 ел, № 49/5редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге составына керүче Мочали торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә **карар** бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең Мочали авылында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2021 елның 13 декабрендә 13:30 сәгатьтә үткәрүне Мочали авыл мәдәният йортында, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Мочали авылы, Ленин урамы, 43а йорт, адресы буенча билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“2022 елда үзара салым кертүгә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авылы, Мочали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме?:

- Мочали  авылының Ленин, Октябрь, Киров урамнары буенча юлларга вак таш салу;

- Мичурин урамы, 38 нче йорт - Бездна авылы аша Суворов күпере яңа материал өстәп, вак таш салу нигезенең профилен төзәтү;

- Ленин урамы, 29 йорт – Киров -Первомайская урамы, адресы буенча гамәлдәге юлның яңа материалын өстәп вак таш салынган нигезләрнең профилен төзәтү;

- Мочаль авылында паркны төзекләндерү;

- Мочали авылы чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: янгын автомашинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, граждан-хокукый шартнамә буенча машина йөртүченең хезмәте өчен түләү)

“ӘЙЕ”                                                    “КАРШЫ” ”.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге башлыгының «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Матак авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 18 ноябрендәге 25 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районының Матак авыл җирлеге башлыгы:                    В.П.Мердеев